**Сохранение и развитие национального образования и культуры в русской школе.**

Национальное образование в русскоязычной школе представляет собой многогранную и разностороннюю структуру.

Воспитание высококультурного, интеллигентного человека, знающего родной язык, историю и обычаи своего народа – одна из основных задач.

Школа имени академика Р. З. Сагдеева - многонациональная семья, в которой царит уважение к традициям и обычаям народностей, проживающих в республике.

Бүгенге көндә мәктәбебездә милли мәгарифкә зур игътибар бирелә. Яшь буынга туган телне, әдәбиятны, тарихны, мәдәниятне өйрәтү иң әһәмиятле бурычлардан санала.

**Укучыларның милли составы**

| Укучылар саны | татар | рус | чуаш | азербайҗан | Катнаш гаиләләр |
|---|---|---|---|---|---|
| 550 | 342 (39,3%) | 145 (26,3%) | 51 (9,2%) | 2 (4,2%) | 10 (21%) |

Мәктәптә белем алуы укучыларның 100% да татар телен туган тел буларак өйрәнә.
3 еллык нәтиҗәләр буенча өлгереш-100%, белем күрсәткеченең үсеш динамикасы таблицада да ачык чагыла.

| Предмет | 2017/2018 | 2018/2019 | 2019/2020 |
|---|---|---|---|
| Татар теле/ татар әдәбияты (татар төркемнәре) | 90/ 98% | 94/ 97,5% | 99/ 99,7% |
| Татар теле/ татар әдәбияты (рустелле төркемнәр) | 90,5/ 90,5% | 91/ 95% | 93/ 96% |

Мәктәптә милли мәгарифне үстерүгә барлык шартлар да тудырылган. Һәр бала нинди милләттән булуына карамастан, бик теләп татар телен өйрәнә, халкыбызның гореф-гадәтләрен, милли йолаларын белеп үсә, һәр төрле сыйныфтан тыш чараларда актив катнаша.

Телне саклауда мәктәпнең туган тел һәм әдәбияты укытучыларының өлеше зурдан. Мәктәптә югары белемле 5 укытучы хезмәт куя.

Алар һәрвакыт яңалыкка омтылып, заман сулышын тоеп, укыту-тәрбия процессына иҗади якын килеп эшлиләр.

Узган уку елында Буа шикәр заводы коллективы хезмәткәрләре өчен безнен мәктәп укытучылары татар теленә өйрәнү буенча интенсив курслар алып барды.

Укытучыларның һөнәри бәйгеләрдә ирешкән нәтиҗәләре слайдларда ачык чагыла.

Укучыларда милли мәгарифкә, татар мәдәниятенә хөрмәт, кызыксыну уятуда мәктәпнең Р. Харис исемендәге “Сәнгатьне күрү” музее зур әһәмияткә ия. Музейда әлеге юнәлеш буенча даими эш алып барыла.

Бөтендөнья татар конгрессының күчмә утырышында катнашкан дәрәҗәле кунаклар өчен укучылар көче белән зур күргәзмә, музейда тирән эчтәлекле экскурсия оештырылды, укытучылар тарафыннан ачык дәресләр күрсәтелде.

Менә 6 ел рәттән мәктәптә “Шәҗәрәләр – нәсел агачы” төбәкара фәнни-гамәли конференциясе уздырылып килә. Ул Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен оештырыла.

Шулай ук ел саен ТР Язучылар берлеге белән “Киләчәге бар милләт без, Шәхесләргә бай милләт без” исемендәге республикакүләм Ренат Харис укулары үткәрелә. Һәр елны Ренат Харис исемендәге премиянең төрле номинацияләрендә мәктәп укучылары да лауреат исеменә лаек була.

Әлеге чаралар барысы да укучыларда туган телебезгә, илебезгә, аның атаклы шәхесләренә ихтирам хисләре тәрбияләү максатыннан үткәрелә.

Милли мәгарифне үстерү юнәлешендә алып барыла торган эшнең нәтиҗәлелеген республикакүләм фәнни–гамәли конференцияләрдә, төрледән–төрле бәйгеләрдә ирешелгән күп санлы уңышларыбыз раслый.

Татар телен укытуны камилләштерү буенча рустелле укучыларны аралашырга өйрәтүдә, инновацион проект буларак, “Сәлам!”УМК ты кулланыла.

Телне саклау һәм пропагандалауда олимпиадаларның да роле зур. Предмет буенча район, республика олимпиадаларында укучыларыбыз ел саен катнашып, үзләренең белемен тикшерә.

| Уку елы | Җиңүче | | | Призёр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Татар теле | Тат.әд. | Рустелле укучылар өчен тат.теле | Татар теле | Тат.әд. | Рустелле укучылар өчен тат.теле |
| 2018/2019 | 1 | 1 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| 2019/2020 | 1 | 1 | - | 1 | 1 | 1 |
| 2020/2021 | 1 | - | - | 4 | - | - |

Мәктәптә милли бәйрәмнәр еш үткәрелә. “Нәүрүз”, “Карга боткасы”, “Масленица», «Әбием сандыгы”, Сабантуй кебек бәйрәмнәрдә, сыйныфтан тыш чараларда төрле милләт балалары бик теләп катнаша.

Узган уку елында укучыларыбыз ТНВ каналында “Тамчы-шоу" интеллектуаль бәйгесендә чыгыш ясады. Өч укучыны берләштергән “Тамчылар” командасы әлеге бәйгедә уңышлы чыгыш ясап, Призер Дипломына лаек булды.

«Милли мультfest» республика балалар кинофестиваленең муниципаль этабында катнашып, Татарча анимацион фильмнар номинациясендә укучыларыбызның эшләре I һәм III дәрәҗә Дипломга лаек булды.

Мәктәпнең эшчәнлеге республиканың “Мәгариф” журналы (2020 нче ел 4 нче санында) урын алды. Анда мәктәп турында мәкалә, шулай ук укытучыларыбызның дәрес эшкәртмәләре басылып чыкты.

2021 нче ел Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде. Мәктәптә бу ел кысаларында үткәреләчәк сыйныфтан тыш чаралар планы төзелде һәм әлеге план нигезендә системалы эш алып барабыз.

**Нәтиҗә ясап**, шуны әйтергә була: Халкыбыз бездән милли рухлы, милли үзаңы югары дәрәҗәдә булган, телне, гореф-гадәтләрне саклый белүче, республика, район үсешенә зур өлеш кертердәй шәхесләр көтә. Милли мәгарифкә булган игътибарны тагын да көчәйтеп, аны үстерүдә бердәм эш алып барырбыз дип ышанып калабыз.